

Нур Әхмәдиев

# Мыраужанның туган көне

Балалар өчен шигырьләр, табышмаклар,
поэма һәм шигъри әкият

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2013

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ә87

Рәссамы Рөстәм Хәбибуллин

Әхмәдиев, Н. Г.

Ә87 Мыраужанның туган көне : балалар өчен шигырьләр, табышмаклар, поэма һәм шигъри әкият / Нур Әхмәдиев ; [рәссамы Рөстәм Хәбибуллин]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 103 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-02479-2

Китапта язучының балалар өчен төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре, табышмаклары, поэмасы һәм шигъри әкияте тәкъдим ителә.

Җыентык мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына адреслана.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02479-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2013
© Әхмәдиев Н. Г., 2013

# Хәерле иртә!

– Хәерле иртә, әни, – дим, –
Әти, – диям, – әби, – дим.
Әби әйтә:
– Син минем
Бигрәк үскән бәбием.

Хәерле иртә телимен
Чәчәге, үләненә.
Чебиләрнең, җим сорап,
Яныма килгәненә.

Песигә дә телимен
Һәм кәҗә бәтиенә.
Акбай «һау» ди
«Хәерле
Иртә!» дип әйтүемә.

Тылсымлы сүзләрдер ул
Шушы «Хәерле иртә!».
Озын көннең буена
Мине хәерле йөртә.



# Хәерле кич!



Көн сүрелде. Ятагына
Тәгәри нурлы кояш.
Көтү кайта. Җилем тулгач,
Сөзгәк сыер да юаш.

Эңгер-меңгер төште диеп
Хафаланмыйм әле һич.
Туганнарым, дусларыма
Телимен хәерле кич.

# Тәмле йокы, тәмле төш!

Кабат кояш чыккан дисәм,
Тулган ай карый икән.
Көне буе чабып йөргәч,
Аяклар арый икән.



Күзләрне йокы басты,
Рәхәт соң юрган асты.
Кача күрмәсен йокы,
Әбием, дога укы!

Йокыга китәр алдыннан
Калды минем тик бер эш.
Онытмыйм һич тә әйтергә:
– Тәмле йокы, тәмле төш!

# «Гөмбә»

Ул «гөмбә»не күрергә
Урманга барасы юк,
Эзләп тә табасы юк.
Әнә, әнә тегендә –
Безнең ишек төбендә
Тора җәен, көзен дә.

Үзе шундый шәп «гөмбә»!

Берьюлы анда сыя
Мәхмүт, Габитҗан, Зыя,
Ләйлә, Нияз һәм Гөлнур,
Зөлфия белән Зиннур.

Акбай да кергән була,
Кемгәдер өргән була.
Күңелле бит аңа да,
Шаярып йөргән була.



# Бозавым

Зурдыр дип уйламагыз,
Кичә генә туган ул.
Кичә генә туса да,
Минем буе булган ул.



Колаклары тырпайган,
Зәңгәрсу-кара күзе.
Сөйләшәбез дигәндәй,
Миңа карый ул үзе.

Үзе кызыл тун кигән,
Маңгаенда кашкасы.
Безнең бозаудан матур
Була алмас башкасы.

Аяклары нәзектер,
Елык-елык тиресе.
Ничек елкылдамасын,
Ялап торгач әнисе!

Бигрәк шаян ул бозау,
Исәбендә гел уйнау.
Сикереп чапмак була,
Таеп кына егыла.

Бозавым таймас өчен,
Хәйләсен мин табармын, –
Аякларына аның
Тимераяк тагармын.



# Яңа чана

Малайлар тау буенда,
Кич җиттеме – уенда.
Алар чана шуалар,
Берсен берсе куалар.



Карагыз сез Илбәрне:
– Узам, – ди ул, – җилләрне!

Авызы гел колакта,
Ә колагы – еракта.
Күпләр кызыга аңа,
Чанасы шул өр-яңа.

Ярты тауны төшүгә,
Чү, чанага ни булды?
Сикертмәдә сикерде дә
Яны белән борылды.
Егылып калды Илбәр,
Чананы куа җилләр.

Яңа шул, һәй, чанасы,
Туктарга юк чамасы...



## Чирләрсең

Кыш бабай килгән безгә
Бик ерактан – котыптан.
Карлар сибелеп тора
Өстендәге толыптан...

Җем-җем иткән толыбы
Ап-ак мамык якалы.
Бабаебыз ай-яй карт:
Билгә җиткән сакалы.

Куыша безнең белән,
Узыша безнең белән.
Җырлый, бии, сөйләшә,
Күп-күп бүләк өләшә.

Әй, Кыш бабай, туныңны
Салып уйна, тирләрсең.
Тышта буранлап тора,
Суык тиеп чирләрсең.

